# ЧИШМӘ БАШЫ

**МБМБУ "Арча шәһәренең гомуми үсеш бирү төрендәге 7 нче номерлы "Балачак" балалар бакчасы"**








| №2 | ДЕКАБРЬ | 28.12.2024 |
|---|---|---|

Җир өстенә аклык-пакьлек алып килгән
Яңа ел бәйрәмк котлы булсын!
Киләсе елның 365 көне дә бәхет-шатлык кына китерсен.
Аткан таңнарның барысы да алсу булсын.
Тормыш юлларында шатлыклы очрашулар,
Бәхетле елмаюлар, куанычлы мизгелләр күп булсын!

# ЯҢА ЕЛ БӘЙРӘМЕ



**Яңа ел килә**

Күңел көтә яңа елның
Ак мамыктай карларын,
Ап-ак шәлле агачларын
Эх зәхәр бураннарын.
Ак басуны ярып үткән
Тирән чана юлларын
Истә әле зарыкканнар
Көтеп яңа елларын.
Ул теләкләр, ул бүләкләр
Яңа елнын көнендә,
Рәхәт чаклар, кызык чаклар
Онытылмый бүген дә.
Менә тагын әкрен генә
Атлап килә Яңа ел,
Теләкләрем тормышыма
Ашсын иде дим быел.

**Гульфия Гизатова**

Яңа елны бәйрәм итә башлау безнең эрага кадәрге 3 меңьеллыкка - Месопотамиягә барып тоташа. Вавилон халкыннан иудейлар, аннары греклар аша бу вакыйга Көнбатыш Европага кадәр килеп җитә. Аннары инде Җир шарының башка илләренә тарала.
1700 елда Петр I әмере буенча 1 гыйнвар көнне билгели башлыйлар. Әлеге карар буенча Яңа ел бәйрәменә өйләрне Гостиный дворда куелган үрнәк буенча нарат, чыршы ботаклары белән бизәргә кирәк була. Бәйрәм рухы тудыру өчен кешеләрнең бер-берсен котлавы мәҗбүри куела.
Ул чорда Мәскәүдәге Кызыл мәйданда утлы өермә уйнатыла, туплардан һәм мылтыклар-дан салют бирелә. Мәскәүлеләр өйләре янында мушкеттан атар¬га һәм ракеталар очырырга тиеш булалар. 1873 елда Александр Островский «Снегурочка» пьесасын яза. Кар кызы, Кыш бабайның оныгы буларак, XX гасырның 50нче елларында Кремль чыршы бәйрәмнәре өчен язылган сценарийлар аша танылa.
1917 елгы инкыйлабтан соң Яңа елны һәм Раштуаны бәйрәм итү туктатыла.
1935 елда исә, балалар бәйрәме буларак, кире кайтарыла.
1937 елның гыйнвар башында Мәскәүнең Колонналы залында беренче тапкыр рәсми Чыршы ут¬лары кабызыла. Аннан соңгы ел¬ларда ил буйлап меңнәрчә чыр¬шылар бизәлә.
1947нче елның 23 декабрендә СССР Югары Советы президиумы указы белән 1 гыйнвар бәйрәм һәм ял көне дип игълан ителә. Ә ел башындагы рәсми ял көннәре 2005 елдан кертелә.
Балаларны хәзер Яңа ел белән Кыш Бабай һәм Кар кызы котлый, бүләкләр өләшә, бәйрәм хисе алып килә. Татарлар әле дә әлеге бәйрәмне гаилә белән берлектә билгеләп үтә һәм сәгать чыңыннан соң туганнарын, дусларын, күршеләрен котлый. Кайберәүләр исә бәйрәм кичендә якыннарын чәк-чәк белән сыйлап калырга ашыга.
Еллар уза, гасырлар үтә, буыннар үзгәрә. Ләкин Яңа ел бәйрәме әле дә яңа ышанычлар багларга, хыялланырга һәм яхшыга өметләнергә этәрә. Без дә, борынгы бабаларыбызга карап, бу бәйрәмне матур һәм җылы атмосферада үткәрик. Бәйрәмне генә түгел, тулаем бер елны!

**Төзеде: Рамазанова Л.Ф.**

# ЧИШМӘ БАШЫ

МБМБУ "Арча шәһәренең гомуми үсеш бирү төрендәге 7 нче номерлы "Балачак" балалар бакчасы"




## Яңа ел хакында кызыклы фактлар

1.Россиядә Яңа ел бәйрәменә куела торган беренче чыршыларны алма, конфетлар белән бизәп сата торган булганнар.
2.Чыршы астына бүләк кую гадәтен алманнар уйлап тапкан. Россиягә әле ул гадәт XIX гасырның икенче яртысында гына килеп җиткән.
3.Россиядә Яңа елны курант тавышлары астында каршы алабыз. Бу музыканы махсус чүкеч ярдәмендә хәрәкәткә килгән 11 кыңгырау тудыра.
4.Гыйнварның соңгы якшәмбесендә Дөньякүләм кар көне билгеләп үтелә
5.Японийдә Яңа ел алдыннан барлык таныш-белешкә бәйрәм открыткасы җибәрү гадәте яшиш. Почта хезмәткәрләренең эше авыр – өстәлдә кайчак бер метр биеклегендәге открытка өеме барлыкка килә икән. Әмма алар өчен кырыс закон бар – һәр открытка 1 гыйнвар көнне иясенә барып җитәргә тиеш.
6.Исландиядә Кыш бабай урынына – Йоуласвейн исемле 13 тролль йөри.

Кытайда Яңа елны ике тапкыр бәйрәм итәләр. Берсе – 31 декабрь төнендә, икенчесен Кытай календаре буенча. Анысының төгәл датасы юк, ай календаре буенча билгеләнә.

Элек Яңа елны 1 сентябрьдә билгеләп үтә торган булганнар. 1699 елның 20 декабрендә Петр I яңа вакыт санау системасына күчә һәм Яңа елны бәйрәм итү 1 гыйнварга күчерелә.





## ТӘМЛЕ БУЛСЫН!

Яңа ел өстәле өчен ризыклар-бәйрәмнең аерылгысыз өлеше. Хуҗабикәләр аны алдан ук уйлап куялар, табын янына ниндидер яңалык бирергә яки иске рецептларны камилләштерергә тырышалар. Астрологлар киләсе ел талисманы өстенлекләре булган ашамлыклар исемлеген килештерергә киңәш итә. Көнчыгыш гороскобы буенча 2025 ел яшел агач Елан елы булачак. Яңа ел өстәлендә нинди ризыклар булырга тиеш, ә нинди ризыклардан баш тарту яхшырак?
Елан – гади җан иясе түгел. Бер яктан, аның образы куркыныч тудырса, ә икенче яктан — тынычлык һәм сылулыкны гәүдәләндерә. Көнчыгышта елан зирәклек һәм тынычлык символы булып санала. Аның белән кем дуслаша — шул кыенлыкларны җиңә алачак. Үз чиратында, яшел төс яңару, гармония һәм чәчәк ату билгесе булып хезмәт итә. Киләсе елның символы бәйрәм өстәлендә ит һәм балык ризыклары булуга каршы булмаячак. Аларның теләсә кайсысын «елан темасы»нда бизәргә була, һичшиксез яшел яшелчәләрдән гарнир рәвешендә дөрес төс төсмерләре өстәргә кирәк. Бәйрәм өстәле байлык һәм агач стихиясен символлаштырса яхшырак. Монда яшелчәле ризыклар ярдәм итәчәк. Нәфислек һәм сыгылмалылык өчен диңгез продуктлары һәм балык җавап бирә. Ризык тукландыру белән бергә, бәйрәм атмосферасына да йогынты ясый һәм энергия бирә. «Елан символизмы – саклык, зирәклек. Артык майлы ризыклар уңышлы сайлау булмаячак, чөнки елан — шул исәптән затлылык һәм төзлек символы.

**Бәйрәм табынына каз пешерү ысулы.**

Казны әзерләү өчен:

- 10 литр җылымса су
- 700 грамм тоз
- 2 тырнак сарымсак
- 6 дәфнә (лавр) яфрагы
- кипкән шөет (укроп) орлыклары
- 10-15 бөртек кара борыч

Казны пешерү өчен:


- 3,5 - 4 кг каз

## МАВЫКТЫРГЫЧ УЕННАР

**“Уен-лабиринтлар”**

Буталчык юллар яки сызыклар сурәтләнгән үсешле рәсемнәрне үтү өчен юл капланган жирләргә эләкмәскә тырышып, керүдән чыгуга кадәр дөрес маршрут табарга кирәк.
Лабиринтлар баланың логик фикерләвен, максатка ирешә белүен үстерә.
Бу гади уен сабырлыкны үстерә. Моны хәтта уен барышында баланың үз - үзен тотышы буенча да күрергә мөмкин-лабиринттан чыгу юлын тапмаса, ул никадәр тиз бирешә яки нервлана башлый. Бала уенда үзен никадәр түземсез тотса, шулкадәр ешрак аны монд ый уеннарга җәлеп итәргә кирәк, әкренләп сабырлык һәм катлаулы ситуацияләрне тыныч кабул итү булдырырга кирәк.

**Төзеде: Сафиуллина Алинә Фәрит кызы.**



**“Кышкы фигура"**

“Диңгез фигурасы” уенына охшаш, тик биредә кышкы фигураны сурәтләргә кирәк. Алып баручының «Буран бер дулый, буран ике дулый, буран өч дулый, кышкы фигура урынында калыр!» дигән сүзләреннән соң, уенда катнашучылар төрле фигуралар ясап тын калалар. Селкенгән кеше уеннан чыга.

• 7 әче, яшел алма (антоновка сорты булса яхшы)
• 1 уч төшле каражимеш
•0,5 аш кашыгы аджика
• 1 аш кашыгы майонез
• пешерү өчен махсус пакет

Чиләккә 10 литр җылымса су салырга, анда 700 гр тозны эретергә, шуңа сарымсак, дәфнә яфрагы, кара борыч, шөет орлыгы өстәргә. Шушы суга казны салырга, чиләкнең өстен капларга. Каз тулысынча суга күмелергә тиеш. Бүлмә температурасында 1 тәүлек тотарга. Болай эшләүнең өстенлекле ягы шул: каз тулысынча тәмләткечләрне һәм тозны үзенә сеңдерә.
Икенче көнне казны судан алып, салфетка белән корытабыз. Аджика һәм майонезны кушып, казның эчен-тышын сылыйбыз. Алманың үзәген алып, 4 өлешкә бүләбез. Каражимешне юабыз, төшен алабыз. Аннары алманы кара җимеш белән катнаштырып, каз эченә тутырабыз
Казның ярылган җирен тегәбез һәм пешерү өчен махсус пакетка тыгабыз. Пакетның өстен энә белән берничә җирдән тишеп, духовкага 2 сәгатькә куябыз. Духовканы алдан җылытып кую зарур. Пешерү өчен оптималь температура - 180 градус. Каз пешкәннән соң, аның суынганын көтәргә кирәк. Телемләп турап, алма һәм каражимеш белән бизәп табынга чыгаралар.





**“Кошлар һәм буран”**

Алып баручы әйтә:" Кыш-кошлар өчен кырыс вакыт. Көннәр суык, бураннар дулый, һәм кошлар сыену урыны эзли. Әйдәгез, һәр кош өчен өй ясыйк!». 4 пар уенчыны һәм 5 катнашучыны парсыз чакыралар. Һәр парның катнашучылары кулга-кул тотынышалар. Алар йортны сурәтли. Башка катнашучылар, канат каккан кебек, кулларын җәеп, алар тирәсендә йөгерәләр. Музыка тынгач, алып баручы “Буран килде” ди, “кошлар” “йортка керәлә” (ягъни парның уртасына басарга) тиеш. “Йорт” җитмәгән кеше уеннан чыгарыла.



**Төзеде:Салахиева Р.М.**

Декабрь бураннары, кышкы салкыннарда җемелдәгән
йолдызлар алып килгән Яңа ел белән котлыйм!
Бәйрәмегез мөбәрәк, ризык тулы өстәлегез түгәрәк,
күңелле, куанычлы булсын

**Яңа ел бизәге "Кыш Бабай"**

Кадерле дуслар! Бик тиздән 2024 ел, безнең белән саубуллашып, тарихка китәчәк. Ә аңа алмашка Яңа 2025 ел ашыга!
Яңа ел бәйрәменең үзеннән бигрәк, аны көтү, аңа әзерләнү кызыграк, тылсымлырак бит ул, әйеме? Нәкъ әнә шундый өр-яңа өметләр белән өр-Яңа елны көтү кәефе тудыра торган, матур Яңа ел бизәге "Кыш Бабай" ясарга тәкъдим итәбез.
Материал: кәгазь тәлинкә, төсле кәгазь, клей, кайчы, фломастерлар.

1. Кәгазь тәлинкә алыгыз да, аны урталай бөгеп, я кисегез.
2. Кызыл кәгазьдән өчпочмак кисеп алыгыз - бу башлык булачак, аннары - ике түгәрәк (берсе кызыл кәгазьдән, икенчесе ак), бу борын һәм бүреккә помпон булачак. Алсу кәгазьдән тагын 2 түгәрәк кисеп алыгыз - бу битләр булачак.
3. Алга таба Кыш Бабайның барлык өлешләрен, рәсемдә күрсәтелгәнчә, бөккән тәлинкәгә ябыштырабыз.
4. Күз һәм елмаю детальләрен маркер белән ясагыз.
5. Кыш бабай әзер.

Яңа ел мөбәрәк булсын!

**Кыш бабай остаханәсе "Яңа ел уенчыклары"**

Сатып алынган уенчыклар , берсүзсез, матур, ләкин безнең үзебез ясаган, кул җылыбызны кушып иҗат иткән уенчыкларыбыз тагын да кадерлерәк һәм бер дә кибеттән алган уенчыклардан ким түгел.Элек-электән, яңа елны каршы алганда, өйдә чыршы бизәү гадәткә кереп киткән. Кайберәүләр, бәйрәмгә әзерләнгәндә, чыршы эзләүгә күп вакыт сарыф итәләр, агачның мөмкин кадәр зуррагын, куерагын алырга тырышалар. Мондый агач өйдә күңел ачарга, биергә дигән мәйданны биләп, кысрыклап тора, җитмәсә, ылысы коелып идәнне чүпли, өйне җыйнаксыз итә. Ә ике атнадан аны чыгарып ташлыйсы була, баскычларда, юлларда дөнья кадәр корыган ылыс коелып кала. Гыйнвар уртасында чүплек башларында аунап яткан корыган чыршы-нарат кәүсәләрен күреп, кемнәрнең генә үзәге өзелми икән?

Зур агачны әрәм итмичә генә дә Яңа ел кичәсен кабатланмас уздырырга була. Моның өчен өйнең стеналарын матурлап бизәргә мөмкин. Беренче ысул һәркемгә билгеле. Урманга чаңгы яки чана шуарга барган вакытта, җирдә аунап яткан ботакларны җыю. Стеналарны рам алып, чыршы ботакларын куеп бизәү. Ботакларны шулай ук уенчыклар белән бизәргә мөмкин. Икенче




**Төзеделәр: Аглиуллина А.Р., Сайфуллина Л.Р**

ысул элегә яңача. Шулай ук рам алып бизәргә ярый. Ул рамны түгәрәкләр белән чыршы формасында ябыштырабыз. Бу түгәрәкләрне ташлый торган әйберләрдән ясап була. Скотч һәм кәгазьдән калган түгәрәкләр дә ярый. Аларны бер үк киңлектә кисәргә кирәк. Түгәрәкләрне ябыштырганнан соң, түгәрәкләр эченә кечкенә бүләкләр куябыз. Балаларга ул сөенеч, аларны алып, алар режиссерлык уеннарын башкара алалар.

**Кирәк:**

- фоторам;
- скотч түгәрәкләре;
- пычак;
- буяу;
- пумала;
- су савыты;
- клей;
- киндер уенчыклары.

1. Фоторам эчендәге ак кәгазьне “юеш ысул” белән зәңгәргә буыйбыз.
2. Буяу кипкән арада 2-3 см киңлектә түгәрәкләр кисәбез.
3. Түгәрәкләрне ак гуашь төсенә буыйбыз.
4. Түгәрәкләрне ябыштырабыз.
5. Түгәрәкләрнең эчен киндер-уенчыклары белән бизибез. Уенчыкларны пластилин белән ябыштырсаң унайлырак, чөнки аларны теләгән вакытта алыштырырга була һәм балалар өчен файдаланырга.

### Елан елыннанниләр көтәргә?

2025 ел — яшел агач елан елы. Ул безне ниләр белән гаҗәпләндерер, беләсегез киләме?

Кытай мәдәниятендә зирәк һәм хәйләкәр елан еш кына тылсымлы ярдәмче һәм серләрне саклаучы ролен уйный: авырлыкларны җиңәргә ярдәм итә һәм дөрес юл күрсәтә.Елан — тыныч хайван, ләкин үзен яклый белә, шуңа күрә аны ачуландырмау яхшырак. Ләкин ни өчен ул агачтан, өстәвенә яшел төстә, дисезме? Көнчыгыш йолдызнамәсендә һәр ел саен, ”хуҗа" хайваннан тыш, тагын бер элемент яки стихия алмашына: алтын, ут, су, җир һәм агач. Агачның символик төсе — яшел. Бу кагыйдәләр буенча "агачлылык" уңыш һәм үсеш вәгъдә итә, ә яшел төс сыгылмалылык, тынычлык һәм, иминлекне югалтмыйча, шартларга җайлашу сәләте турында сөйли. Күрүегезчә, алдагы елның билгеләре начар түгел. Елан елыннан нәрсә көтәргә? Бер яктан, Еланны тыныч, акыллы хайван дип атыйлар. Икенче яктан — Елан вакытының еш кына дөньяга драматик вакыйгалар һәм катаклизмнар китерүе билгеле.Мәсәлән, 1881 елда народоволецлар император Александр IIне шартлаталар. 1905 елда революция була. Октябрь революциясе дә Елан елында булган. 1929 елда АКШта — Бөек депрессия, ә 1941 елда СССРда Бөек Ватан сугышы башлана. Шулай ук хуҗасы Елан булган 2001 елда 11 сентябрьдә АКШ тарихында иң зур теракт булды. 12 ел узгач, Бенедикт XVI Папа тәхетеннән ваз кичте — соңгы 600 ел эчендә Папаның ваз кичүенең беренче очрагы. Борчулы исемлек 2025 елда тулыланмас дип өметләнәсе килә. Әмма астрологлар борылышлы вакыйгалар башка булмаячак, дип кисәтә.

## *КОНСУЛЬТАЦИЯ!*

### Кышкы чорда куркынычсызлык чаралары.

Кыш - тылсымлы вакыт. Кыш - хуш исле чыршылар, күңелле бәйрәмнәр вакыты. Ләкин кыш үз куркынычларын китерә. Елның салкын вакытында иминлекне саклау өчен киңәшләр.

1.Кояштан саклаучы крем файдаланыгыз – балаларның тәнен кояшның зарарлы нурларыннан җәйге чорда гына түгел кышкы айларда да сакларга кирәк. Кояшның нурлары кар яки боздан чагылуы биткә зарарлы, хәтта туры нурлардан кебек.

2. Баланы урамга ничек дөрес киендерергә: баланы урамга җибәргәнче аның ничек киенгән карагыз: җылы, берничә кат кием. Мөмкин кадәр йонлы киемнәр сайлагыз. Йон нык һәм сыгылмалы материал. Кышкы кием баланың зурлыгына туры килергә тиеш һәм хәрәкәтләрне чикләргә тиеш түгел. Бу аеруча аяк киемнәре өчен актуаль. Артык кысан итекләр кан басымын тарайталар, нәтиҗәдә аяклар тизрәк суыналар. Аяк киемен сайлаганда бер размерга зуррак алыгыз. Итекләр су үткәрмәүчән булырга тиеш.

3. Чанада шуу: Балалар чанада шуарга яраталар, шуу чанада , ләкин алар иминлек кагыйдәләрен белергә тиеш.

Чанада шуатырган урын ачык булырга тиеш. Баланың юлында агачлар һәм куаклыклар булмаска тиеш. Шулай ук тауның ахыры транспорт юлына чыгарга тиеш түгел.


4. Туңу билгеләре: Ешрак борын, колаклар, яңаклар һәм бармаклар туңа. бөтенесе азапланалар борын, колаклар, яңаклар һәм бармаклар. Туңу билгеләре: кымыржу, телсезләнү, чәнчеп алу яки пешерү. Җәрәхәтләнгән өлешләр агара, кызара яки зәңгәр була.

5. Әгәр дә бала өшесә:

- иң беренче җылы урынга барырга вәҗеп;
- җәрәхәтләнгән өлешләрне чиста йомшак тукыма белән уыгыз, кар белән умагыз;
- салкын һәм юеш киемнәрне коры, йомшак, иркен киемгә алыштырыгыз;
- организмны акрынлап җылытыгыз: какао яки чәй эчерегез;
- ярдәмгә табипны чакырыгыз.

6. Шарф, бияләйләр һәм перчаткалар. Шарфны кием эченә кертеп калдырыгыз. Өстәмә бер кием перчаткалар яки бияләйләр булырга тиеш, чөнки перчатка югалырга, яки чыланырга мөмкин.

Саф һавада уеннар чыныгу һәм профилактика өчен бик мөһим. Ләкин урам-га чыгар алдыннан яхшылап әзерләнегез. **Төзеде: Нәҗипова Г.И.**




Еланның һәрвакыт уңай һәм тискәре сыйфатлары булган. Бер яктан, ул зирәклек һәм тынычлык символы булып санала, икенче яктан — мәкерлелек һәм хәйләкәрлек. Борынгы заманда кешеләр әлеге горур рептилияләр төрле дөнья үлчәме арасында сәяхәт итәргә һәм киләчәкне белергә сәләтле дип санаган. Шулай булгач, киләсе елда күп мөмкинлекләр ачылыр, күп нәрсәгә ирешә алырга буладыр.

2025 елда Аждаһаны яшел агач Елан алмаштырачак — иң тынычлык сөюче җан иясе. Аңа магнетизм, тапкырлык, хислелек һәм тынычлык хас, ә усаллык, агрессия һәм икейөзлелек аңа хас түгел. Һәм киләсе ел яхшы өметләрне генә акласын өчен, бераз нәзакәтле ерткычка охшарга кирәк. Эшләрдә ашыкмаска кирәк — елланр да озак хәрәкәтсез ятарга һәм бер мизгелдә төгәл һәм тиз ыргы ясарга мөмкин. Сезгә дә кирәкмәгән ыгы-зыгыдан качарга һәм үзегезнең гамәлләрегезне җентекләп уйларга кирәк. Якыннарыгызга нәрсә әйтүегезгә аеруча игътибарлы булу мөһим -сезнең сүзләрегез аларны бик нык «чагарга» мөмкин, хәтта сез берәүне дә рәнҗетергә теләмичә, уйламыйча әйтсәгез дә...
Шуны да онытмагыз: еланнарга иске кабыгыннан котылу хас. Димәк, иске проблемаларны ташлап, киләсе елга “яңартылган килеш” керергә кирәк. Шул ук хәл сезнең тышкы кыяфәтегезгә дә кагыла - әгәр 2025 елда сез яшәрүгә курс алсагыз, процедуралар файдага гына барачак.

Русиядәге күренекле астролог һәм Темпораль тикшеренүләр фонды җитәкчесе Павел Свиридов: «Елан елы башка еллардан аерыла, Русия өчен ул һәрвакыт бик мөһим ел булган, тирән социаль һәм сәяси үзгәрешләр алып килгән. Тагын 12 ел узды һәм без 2013 елан елына кердек. Бу елда илебездә зур үзгәрешләр башланачак», диде. Яшел агач еланны гаилә эчендә яисә якын дуслары белән бергәләп каршылыйлар. Традиция буенча, яшел агач елан киемдә түбәндәге төсләргә өстенлек бирә:

-яшел;
-кызыл;
-сары (алтын)
-соры;
-кара.

Бу елда туган балалар бик акыллы, кызыксынучан, кыю була. Алар һәрвакыт беренчелеккә омтыла һәм, әлбәттә, максатларына ирешә. Елан елында туган кызлар һәм малайлардан сәләтле һөнәр ияләре: музыкант, сәнгать кешеләре, лингвист, психолог, журналист, архитектор, әдәбият белгечләре чыга.

Яңа ел бәйрәменә күптән әзерләнә башлагансыздыр инде, дуслар. Бәйрәмегез күңелле һәм алдагы ел матур үтсен өчен кайбер киңәшләрне дә искә алыгыз.

## *БЕРГӘЛӘП УЙЛЫЙК!*

**• Кыш бабайга ничә яшь?**

Күз алдыгызга китерегез, безнең Кыш бабай әллийчандыр бик күптәннән терлек үрчетү һәм игенчелек белән шөгыльләнүче борынгы кешеләр өчен яшеллек тормыш символы булган. Германиядә, мәсәлән, Урта гасырларда беркайчан да «картаймаган», мәңге яшел, төз һәм озак гомерле чыршыларга табынганнар һәм аларны изге дип санаганнар. Кешеләр аларның ылысларында көч бирә һәм ала торган көч яши дип ышанганнар.

**• Башка илләрдә балаларга бүләкләрне кем тапшыра?**

Англиядә һәм Америкада - Санта-Клаус; Голландиядә - Синте - Клаас; Испаниядә - папа Ноэль; Румыниядә - Мош Джарилэ; Швейцариядә - Юль Томтен; Россиядә - Кыш Бабай.

**• Бөтен планетаның Кыш бабае кайда яши?**

Норвегиядә. Лапландиянең кечкенә шәһәрчегендә Рованиеми иң поляр түгәрәктә, риваять буенча, чын, иң башлы Кыш бабай яши. Бөтен планета балаларына бүләкләр өләшергә өлгерү өчен, ул Раштуа төнендә үзенең сәяхәтенә нәкъ менә шуннан китә. Бирердә онытылмаслык Яңа ел бәйрәмнәре уза, анда гаҗәеп Кызыл калпак кигән гномнарны, гаять зур чаналарга җигелгән матур боланнарны, боз йортларын һәм безгә әкиятләрдән генә билгеле булган башка бик күп нәрсәләрне күрергә була. Ел саен йөзләрчә мең бала һәм олылар Раштуа бәйрәмнәрендә бу гаҗәеп урынга Раштуа әкиятен карарга киләләр.

**Төзеде: Ситдикова Л.Р**

## *Вакыйгалар тезмәсе*




6 декабрь көнне "Саба исемендәге балалар мәктәбе" МБББУ базасында "Бәләкчәләр аланы" республика иҗат конкурсы узды. 3-5,5-7 яшь категорияләре хәм вокал, хореография, нәфис сүз номинацияләре буенча узды. Конкурс нәтиҗәләре буенча безнең тәрбияләнүчеләр җинүче булдылар.




19 нчы декабрь безнең коллегабыз-Нәҗипова Гөлназ Илнур кызы "Ел тәрбиячесе-2025" конкурсында "Туган телдә белем һәм тәрбия бирүче төркем тәрбиячесе" номинациясендә катнашып 1 урынны яулады. Без анын белән бик горурланабыз. Аңа алга табада уңышлар телибез .




6 декабрь көнне Биектауның "Байгыш" балалар бакчасында "Иртәгә юл" төбәкара һөнәри осталык конкурсы узды. Инглиз телен өйрәтү буенча тәрбиячебез Әһлиуллина Алсинә Рәфис кызы 2 урынны яулады. Аны котлыйбыз һәм алга таба уңышлар телибез.



Бакчабызда Яңа Елга багышланган бәйрәмнәр узды. Балалар Кыш Бабай, Кар Кызы һәм төрле геройлар белән күңел ачтылар, мавыгып шигырьләр сөйләделәр, җырладылар, биеделәр, күңелле уеннарда һәм әйлән-бәйлән уйнадылар.Зиннәтле, ялтырап торган зал һәм бизәкле чыршы балаларга могҗиза тудырды.

Бәйрәм азагында балаларга Кыш Бабайдан бүләкләр тапшырылды.